**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.02.2021 № 96

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган торак урын, муниципаль торак фонды, гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында (2018 елның 3 маендагы 372 номерлы редакциядә)

Муниципаль норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү сәбәпле, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентларын раслау турында» 2016 елның 24 июнендәге 424 номерлы карары белән расланган торак урын, муниципаль торак фонды, гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (2018 елның 3 маендагы 372 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.5 пунктта «6) пунктчасында Йорт кенәгәсеннән өземтә (документ коммерция оешмалары тарафыннан бирелгән очракта);» төшереп калдырырга;

2.6 пунктында «Йорт кенәгәсеннән өземтә (документ җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелгән очракта)» сүзләрен «Яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр - Россия Эчке эшләр министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

«8) 14 яшькә җитмәгән гариза бирүче гаиләсенең барлык әгъзалары өчен бала туу турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

9) Мөрәҗәгать итүче һәм/яисә аның гаилә әгъзалары өчен никахны теркәү турындагы таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

10) Ата булуны билгеләү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

11) Никахны өзү турында таныклык - граждан хәле актларын теркәү органнары;

12) Опека билгеләү турында белешмәләр - Россия Пенсия фондына.»;

3.4.1пунктта «йорт кенәгәсеннән күчермәләр» сүзләрен «яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

«8) бала туу турында таныклык;

9) никахлашу турында таныклыклар;

10)ата булуны билгеләү турында таныклыклар;

11) никахны өзү турында таныклык;

12) опека билгеләү турында белешмәләр.»;

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары М.Х.Хабибуллoвага йөкләргә

Җитәкче Р.М. Заһидуллин